ГЛАВА АБСАЛЯМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.2,
с.Абсалямово, 423957

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр урамы, 2 йорт,
Әбсәләм авылы, 423957

Тел.:(85593) 4-26-79, факс:4-26-79, e-mail: Absal.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
№1 “08” ноябрь 2023 ел

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Абсәләм тимер юл разъезы поселогында гражданнарның үзара салым чараларын (бер тапкыр түләүләрне) кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләренә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләренә таянып,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 11 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында"гы нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 22 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм тимер юл разъезы бистәсе, Тынычлык урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан Тынычлык урамындагы 3 нче йорт янында, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезы бистәсендә 2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм тимер юл разъезы бистәсендәге Тынычлык урамы буенча юл-

урам челтәрен норматив хәлгә китерү (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)”.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Әбсәләм авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча кабул ителгәннән соң биш көн дәвамында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева